| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ<br>ПО ОХРАНЕ И<br>ИСПОЛЬЗОВАНИЮ<br>ОБЪЕКТОВ<br>ЖИВОТНОГО МИРА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ<br>ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ ҺӘМ АЛАРДАН<br>ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ |

**Приказ** **Боерык**

«20» марта 2015 года Казань № 35-од

«Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча Комиссия булдыру турында»

20.12.2004 елдан № 166-ФЗ "Балыкчылык һәм биологик су байлыкларын саклау турында"гы Федераль канунның 33.3. маддәсе белән тәңгәл килеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.04.2008 елдан № 264 боерыгы белән расланган, сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен оештыру һәм уздыру Кагыйдәсенең 4 пунктын тормышка ашыру өчен, боерам:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча Комиссия катнашмасын ( 1 нче кушымта);

1.2. Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча Комиссиянең эш тәртибен ( 2 нче кушымта).

2. Хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге башлыгына бу боерыкны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юнәлтүне тәэмин итү.

3. Гамәлдәге боерыкны тикшерүне үз артымнан калдырам.

Идарә башлыгы Ф.С. Батков

20.03.2015 елдан № 35-од
Татарстан Республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм алардан файдалану
Идарәсенең боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча даими Комиссия катнашмасы**

Комиссия рәисе:

Батков Ф.С. – Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсе башлыгы.

Комиссия рәисенең урынбасары:

Шарафутдинов Р.Г. – ДБО " Хайваннар дөньясын саклау өлкәсендә яңа технологияләр кертү үзәге" директоры.

Комиссия әгъзалары:

Чиспияков Р.Э. – Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге башлыгы – Комиссия сәркатибе;

Матвеева О.Л. – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлегенең өлкән киңәшчесе;

Колебанова Е.С. –Татарстан Республикасы буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсе сатып алуны тикшерү бүлегенең өлкән белгеч-эксперты ( яраштыру буенча);

Константинов А.С. – Россия балыкчылыгы Урта Идел территория идарәсенең Татарстан Республикасы буенча биологик су байлыкларын күзәтү һәм саклау, дәүләт тикшерүе бүлегенең өлкән белгеч-эксперты (яраштыру буенча);

Богатырев И.А. –ФДБО «Средневолжрыбвод»ның Татарстан Республикасы буенча филиалының төп ихтиологы (яраштыру буенча);

Гатауллин Д.Х. – Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (яраштыру буенча);

Шубин А.А. – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсенең башлыгы ( яраштыру буенча).

20.03.2015 елдан № 35-од
Татарстан Республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм алардан файдалану
Идарәсенең боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча Комиссиянең эш тәртибе**

1. Гамәлдәге Тәртип Татарстан Республикасында сәнәгый балыкчылыкны оештыру өчен балык тоту бүлемтеген алу хокукына килешүнамә төзү бәйгесен уздыру буенча Комиссиянең эшчәнлек кагыйдәләрен билгели ( алга таба – Комиссия).

2. Үз эшчәнлегендә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция кануннары, федераль кануннар, Россия Федерациясе Президентының , Россия Федерациясе хөкүмәтенең һәм башкарма хакимиятнең федераль әгъзаларының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Кануннары, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетының һәм республика башкарма хакимияте әгъзаларының норматив хокукый актлары, балык тоту һәм биологик су ресурсларын саклау өлкәсендә Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм гамәлдәге Тәртип белән куллана.

Комиссия үзенең хокукларын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “**С**әнәгый балыкчылыкны оештыруга балык тоту бүлемтеген алу өчен килешүнамә төзү хокукына бәйгене уздыру һәм андый килешүнамәне төзү” ( алга таба – Кагыйдәләр) 14.04.2008 елдан № 264 боерыгы белән һәм гамәлдәге Тәртип белән тәңгәл килеп тормышка ашыра.

3. Комиссия катнашмасына Россия балыкчылыгы Урта Идел территориаль Идарәсенең балыкчылык буенча федераль агентлыгы, Татарстан Республикасы буенча монополиягә каршы федераль хезмәт Идарәсе һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте әгъзалары вәкилләре кертелә.

Бәйгенең нәтиҗәсендә кызыксынган физик затлар, шул ук санда бәйгедә катнашу өчен гариза биргән ( алга таба- гариза), яки бәйгедә катнашу өчен гариза биргән оешмада эшли торган, ә шулай ук гариза бирүчеләргә карата юридик яктан бәйле булган физик затлар, шул ук санда ул оешмаларның акционерлары, кредиторлары һәм идарә әгъзалары булып килгән физик затлар Комиссия әгъзалары була алмыйлар. Өстә күрсәтелгән затлар Комиссия катнашмасына кергән очракта, Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе ( алга таба - Бәйгене оештыручы) тоткарсыз аларны, бәйгенең нәтиҗәсе белән кызыксынмаган һәм гариза бирүчеләр аларга тәэсир итә алмаган,бүтән физик зат белән алмаштырырга тиеш.

4. Комиссия эшчәнлегенең төп принциплары:

а) гариза бирүчеләргә бәйгедә катнашу өчен тигез шартлар тудыру;

б) вөҗданлы ярыш;

в) биологик су байлыкларын нәтиҗәле куллану;

г) бәйгене уздыру турында ачык мәгълүмат һәм аны уздыруның ачыклагы.

5. Комиссия киләсе функцияләрне үти:

а) гаризаларны кабул итү нәтиҗәләре буенча карар кабул итә;

б) бәйгенең җиңүчесен билгели;

в) бәйгене уздыру белән бәйле, башка эшләр башкара;

Күрсәтелгән функцияләрне үтәү максаты белән, Комиссия киләсе эшләрне башкара:

а) гариза бирүчеләрне, Кагыйдәләрнең 12 пунктта күрсәтелгән таләпләренә туры килүен, ә шулай ук гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның Кагыйдәләрнең 27 пунктына туры килүен тикшерә;

б) бәйгенең теләсә кайсы вакытында, гариза бирүченең 26.07.2006 елдан № 135-ФЗ "Ярышны саклау турында" Федераль канун белән тәңгәл килеп, затлар төркеме катнашмасына керү фактын тикшерә;

в) гаризаларны теркәү өчен җаваплы затка вәкаләтләр бирә;

г) гариза бирүче гаризаны һәм өстәмә документларны биргәннән соң 1 көн эчендә Җәйге оештыручыга мөрәҗәгать итә, кайсы идарәара сорау ярдәмендә, гариза бирүчегә карата, Кагыйдәләрнең 28.1. пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны сорый;

д) гаризалы конвертларны ачу алдыннан яки электрон рәвештә бирелгән гаризаларга рөхсәт ачу алдыннан, ләкин хәбәр кәгазендә һәм бәйге документларында күрсәтелгән вакыттан элегрәк түгел,гаризалы конвертларны һәм электрон гаризаларны ачкан вакытта булган затларга, андый конвертларны һәм электрон гаризаларны ачу процедурасы башланганга кадәр, гаризаны бирү, үзгәртү яки кире алу мөмкинлеге турында хәбәр итә;

е) конвертларны ачу һәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачарга рөхсәт бирү процедурасы башлану вакытына, Оештыручыга килгән барлык гаризалы конвертларны ача һәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачарга рөхсәт бирә.

Гаризалы конвертларны ачканда һәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачарга рөхсәт биргәндә, һәрбер гариза бирүче хәбәр ителә һәм оешманың исеме( юридик затлар өчен), фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (шәхси эшмәкәр өчен) күрсәтелеп конвертларны ачу һәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачарга рөхсәт бирү беркетмәсенә кертелә. Беркетмәдә шулай ук, бәйге белән каралган документларның тулы булуы турында; сәнәгый балык тоту бүлемтекләре өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына кертелә торган түләү тәкъдимнәре турында мәгълүмат , ә шулай ук Кагыйдәнамәнең 28 пунктында каралган мәгълүматлар чагыла.

ж)гаризалы конвертларны ачканда һәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачарга рөхсәт биргәндә, гариза бирүчен (аның вәкиле), гаризада

һәм аңа кушылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларны Комиссиягә аңлатып бирәһәм алар Комиссия белән гаризалы конвертларны ачуһәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачарга рөхсәт бирү беркетмәсенә теркәлә. Комиссия гариза бирүчеләргә өстәмә таләпләр куярга һәм бәйге документлары белән каралган таләпләрне үзгәртергә хокуклы түгел.

з) гаризалы конвертларны һәм электрон рәвештә бирелгән гаризаларны ачу процедурасының аудио язмасын алып бара;

и) гаризаларны, бәйге документлары белән билгеләнгән, таләпләргә туры килүне бәяли;

к) гаризаларны карау нәтиҗәсе нигезендә, гариза бирүчеләрне, Кагыйдәнамәнең 15 пунктында каралган нигезләр буенча бәйгегә кертү яки кертмәү турында карар кабул итә;

л) гаризаларны карап бетергән көндә, утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кулларын куйган, гаризаларны карау беркетмәсен рәсмиләштерә;

м) бәйгегә кертелмәгән гариза бирүчеләргә, Комиссия белән кабул ителгән карарлар турында, гаризаларны карау беркетмәсен рәсмиләштергәннән соң, гариза җибәрелгән рәвештә, 1 көннән дә соңармыйча, белдерү кәгазе җибәрә.

Гаризаны Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр) (http://www.gosuslugi.ru) аша электрон рәвештә бирергә мөмкин булганнан соң һәм гариза бирүче алар белән кулланган очракта, гаризаларны карау беркетмәсенә кул куйганнан соң, Комиссия кабул иткән карар гариза бирүчегә 1 көн эчендә күрсәтелгән информацион системаларны кулланып юнәлтелә;

н) бәйгедә катнашуга 1 генә гариза бирүче кертелгән очракта, гаризаларны карау Беркетмәсен рәсмиләштергәннән соң, 10 эш көне эчендә, килешүнамә проекты аңа тапшырыла;

о) килешүнамә төзүнең иң яхшы шартларын билгеләү максаты белән, билгеләнгән тәртиптә гаризаларны һәм аңа кушылган документларны бәяләүне һәм чагыштыруны тормышка ашыра;

п) гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру нәтиҗәләре нигезендә, һәрбер гаризага (башкаларга карата бәяләү критерий суммалары кимү тәртибендә) тәртип санын билгели;

р)гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсен алып бара;

с) гаризаларны бәяләүне, чагыштыруны уздырган һәм бәйгенең нәтиҗәләрен чыгарган көнне,аның утырышында катнашкан, бөтен Комиссия әгъзалары, гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру Беркетнамәсенә кул куялар;

т) Бәйгене оештыручыга гаризаларны бәяләү һәм чагыштыру беркетмәсен 2 данәдә тапшыра.

6. Комиссия рәисе (ул булмаган очракта – аның урынбасары) Комиссия утырышын уздыра, процедуралы сораулар буенча карарлар кабул итә һәм бәйгенең нәтиҗәләрен чыгара, Комиссия әгъзаларына вакытлыча һәм тиешле сурәттә Комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында хәбәр итә.

Комиссия катнашмасынның гомуми санынннан 50% артык әгъзалары

катнашса, Комиссия утырышы хокуклы дип санала.

7. Комиссия карарлары, утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышлары белән, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителәләр.

Һәрбер Комиссия әгъзасы, Комиссия рәисе һәм Комиссия рәисе урынбасары 1 тавышка ия.

8. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхси катнашалар һәм Комиссия утырышының беркетмәләрен алып баралар.

9. Үзенең эшчәнлегендә Комиссия, гамәлдәге Тәртип белән тәңгәл килеп, Комиссия утырышында кабул ителгән регламент белән җитәкләнә.